| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ СТАРОКУРМАШЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АКТАНЫШСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ИСКЕ КОРМАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ** |
| 423733, село Старое Курмашево,<br>ул. Центральная,дом 29,<br>Тел. 3-44-56 | | 423733, Иске Кормаш авылы,<br>Үзәк ур., 29 нчы йорт.<br>Тел.3-44-56 |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«08» апрель 2021 ел 7

**«Иске Кормаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибен раслау турында» 2007 елның 05 октябрендәге 12 номерлы Актаныш муниципаль районының Иске Кормаш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив-хокукый актларны «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан, Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. «Иске Кормаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибен раслау турында» 2007 елның 05 октябрендәге 12 номерлы Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 9 пунктындагы 3 пунктчасында «Хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Иске Кормаш җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Иске Кормаш авыл җирлеге
Советы Башлыгы И.Ә. Кашбразиев